**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Аксубай муниципаль районы
**муниципаль беремлеге**
423072 Иске Тимошка
Авылы Ленина урамы, 2'
тел. 884344 4-53-40

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Аксубаевский муниципальный район муниципальное образование**
423072 с.Старое Тимошкино
улица Ленина, 27
тел. 884344 4-53-40

Иске Тимошкино авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 21 2021 ел, 22 март

Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез
дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Түләүгә өметсез дип танылган вакытында түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны бетерү тәртибен һәм вакытында түләнеп бетмәгән салымнар, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 02.04.2019, № ММВ-7-8/164@ боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә (алга таба - бурыч):

- бурыч барлыкка килү срогы өч елдан артып киткән очракта, җир салымы һәм үлгән физик затлар мөлкәтенә салым буенча;

- мирас ачылганнан соң 6 ай эчендә мирас хокукы бирелмәгән очракта, үлгән физик затлар мөлкәтенә җир салымы һәм милеккә салым буенча;

2. Салым түләүченең бурычларын исәптән төшерү салым органы әлеге карар һәм салым органының вакытында түләнеп бетмәгән салымнар һәм пенялар, штрафлар буенча бурычлар суммасы турындагы белешмәсе нигезендә башкарыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе П.А.Мулеева